***Роза ХӘМИДУЛЛИНА,***
*Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре*

# ӘДӘБИЯТНЕҢ ЗИРӘК АКСАКАЛЫ

Язучы-прозаик, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Рафис Хәсән улы Сәлимҗанов 1952 елның 1 октябрендә Татарстанның Тукай районы Иштирәк авылында колхозчы гаиләсендә туа. Үз авылында – сигез сыйныф, Түбән Кама шәһәрендә урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, 1970-1975 елларда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында татар теле һәм әдәбияты белгечлеге буенча белем ала. Хезмәт юлын Зәй районының Бигеш урта мәктәбендә тарих һәм татар теле укытучысы булып башлый (1975-1976), аннары район комсомол комитетында инструктор (1976-1977), төбәк газетасы «Дуслык байрагы» редакциясендә хәбәрче (1977-1979) була. Рафис Сәлимҗанов 1979 елдан Чаллы шәһәрендә төпләнеп яши, КАМАЗ заводында эшче һөнәрләренең төрлесен үзләштерә, «Таң йолдызы» газетасында, «Аргамак» журналында, «Мәгърифәт» нәшриятын җитәкли.

Рафис Сәлимҗанов әдәби иҗат эшен узган гасырның җитмешенче елларында балалар өчен кыска хикәя-парчалар һәм юморескалар язудан башлый. Матбугатта беренче хикәясе 1974 елда «Ялкын» журналында басылып чыга. «Акъярда ахырзаман» комедиясен 1988 елда Минзәлә драма театры сәхнәләштерелә. Автор спектакль куелганнан соң туган фикерләре белән «Киңәш» (1997) газетасына биргән мәкаләсендә болайрак итеп уртаклаша: «Халык болай хәйран кабул итте, кул чабып утырган булдылар. Анда фәлсәфә һәм ул фәлсәфәне кешегә җиткерерлек юмор бар иде кебек. Ахырзаманнар дөньяда күп булган. Аны һәрвакыт көтеп яшиләр. Кешелекнең картая башлаган өлешенә ахырзаман идеясе бөтен заманнарда да бик якын:... Көчегездән килгән чаклы, шулай дип яшәгез. Көчегездән килсә... Шул турыда сүз бара бу пьесада».

1984 елда Рафис Сәлимҗановның Татарстан китап нәшриятында унҗиде хикәясен эченә алган «Елан мөгезе» дигән беренче китабы басылып чыга, 1986

елда «Күкеле сәгать» исемле икенче җыентыгы нәшер ителә. Һәм дә бик зур аралык белән 2017 елда «Великий язык тюрков» китабы дөнья күрә.

Рафис Сәлимҗановның әлегә соңгы китабы укучылар күңеленә хуш килде. «Великий язык тюрков» китабы рус телендә басылган, урыс телендә сөйләшүче массаларга да ирештерү өчен эшләнгәне аңлашыла. Автор китапны сатирик повесть-эссе диеп бәяли.

Гасырлар буена милләтебезнең тәңкәсенә тиеп, бәгърен ашап килгән мәсьәлә - телебезнең язмышын тасвирлый язучы. Китап бик күп эзләнүләр, тикшеренүләр нәтиҗәсендә туган. Хәзерге көндә урыс сүзе дип масаючыларга автор үз үрнәкләре ярдәмендә дәлилләп бирү җайларын таба.

Китапның формасы да үзгә, ул тарих, фән, фәлсәфә тармакларын үз эченә ала. Үзләренең иҗатларында төрки-татар сүзләрен кулланучы язучылар: Тукай, Пушкин, Есенин, Фатих Кәрим, Лев Толстой, Гоголь, Лермонтов, Салтыков-Щедрин, Чернышевский, И.А. Крылов, Михаил Шолохов, Михаил Булгаков, Фёдор Тютчев һәм башка язучыларның әсәрләреннән өзекләр белән тасвирлап бирә. Җыентыкта Чаллы шәһәренә 1983 елда килгән Лев Ошанинда искә алып үтелә. Мәктәп еллары истәлекләре белән дә уртаклаша автор. Бөтен булмышы белән тарих белән кызыксынучы кеше буларак тарихка да кагыла Рафис Сәлимҗанов. Анда Чингизхан, Гитлер, Сталин, Хрущев та искәртелеп үтелә. Хәрби терминнарга үз бәясен бирү җаен да таба ул.

Рафис Сәлимҗанов җылы, тарихи, гыйбрәтле, тормышның үзеннән алып язылган әсәрләр иҗат итә. Автор һәрдаим хезмәттә. Ләкин ул әдәби иҗат җимешләрен укучыларга җиткерергә ашыкмый. Үзе дә бу хакта яшерми әйтә. Бер язмасында: «...Язган әйберләр байтак булды. Ләкин... Күп булса, мин аларның 10 процентын дөньяга чыгара алдым. Басылмаган хикәяләрем күп», - ди.

Язучыны барлык укучылар исеменнән күркәм юбилее белән котлыйбыз. Аңа нәкъ үзе әйткәнчә, көченнән килгәнчә тырышып иҗат итәргә язсын, без укучыларга талантлы егетебезнең басылмый яткан әсәрләрен киләчәктә күрергә язсын, ә Рафис Хәсән улына иҗат җимешләрен укучыга җиткерү юлларын табарга бер Аллаһым үзе булышсын, дигән теләкне әйтәсе килә.

*2022 ел*